| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ<br>«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»<br>ЧИСТОПОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>**ЧИСТАЙ<br>ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ** |

***Решение*** ***Карар***

**2022 елның 2 сентябре** **Чистай шәһәре** **№16/4**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәр Советының
«Чистай шәһәре территориясендә
яшел үсентеләр булдыру, тоту һәм
саклау кагыйдәләре турында»
2009 елның 18 декабрендәге 32/4 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2022 елның 6 июлендәге 02-06-2020/Прдп211-22-20000205 номерлы протестын карап чыкканнан соң, муниципаль хокукый актларны хокукый җайга салуны һәм актуальләштерүне камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «Чистай шәһәре территориясендә яшел үсентеләр булдыру, тоту һәм саклау кагыйдәләре турында» 2009 елның 18 декабрендәге 32/4 номерлы карары белән расланган (Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 19.12.2012 ел №18/9, 13.05.2020 ел №46/5, 01.07.2021 ел №8/2 карарлары редакциясендә) сүтелә торган яшел үсентеләрнең бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерү үткәрү методикасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 бүлекнең 4.1, 4.2, 4.3, 4.4, 4.5 пунктларында «(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 28 апрелендәге 154 номерлы карары нигезендә ремонт-төзелеш эшләре өчен ул 3,03 кә тигез)» сүзләрен «( Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 19 декабрендәге 1169 номерлы карары нигезендә ремонт-төзелеш эшләре өчен ул 7,4 кә тигез)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 4 бүлекнең 4.7 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре башлыгы урынбасары М.И. Ксенофонтовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов